ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ
КАТМЫШСКОГО СЕЛЬСКОГО
ПОСЕЛЕНИЯ МАМАДЫШСКОГО
МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
МАМАДЫШ МУНИЦИПАЛЬ
РАЙОНЫ КАТМЫШ АВЫЛ
ҖИРЛЕГЕ БАШКАРМА
КОМИТЕТЫ

ул. Кирова, д.74, с. Катмыш,
Мамадышский район,
Республика Татарстан, 422177

Киров ур., 74 нче йорт, Катмыш авылы,
Мамадыш районы,
Татарстан Республикасы,422177

тел.(факс): (85563) 2-72-03 e-mail: Katmish.Mam@tatar.ru, www:mamaduysh.tatarstan.ru

Решение
"15" июль 2019 ел

Карар
№ 2-46

Татарстан Республикасы Мамадыш муниципаль районы Катмыш авыл җирлеге Советының 17.09.2018 ел, 4-36 санлы карарына үзгәрешләр һәм өстәмәләр кертү турында

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» Федераль законга үзгәрешләр кертү хакында» 2019 елның 1 маендагы 87-ФЗ номерлы Федераль закон, «Татарстан Республикасы Мамадыш муниципаль районы Катмыш авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге Уставы нигезендә, Мамадыш муниципаль районы Катмыш авыл җирлеге Советы
КАРАР КАБУЛ ИТТЕ:

1. Татарстан Республикасы Мамадыш муниципаль районы Катмыш авыл җирлеге Советының 2018 елның 17 сентябрендәге 4-36 номерлы карары белән расланган «Татарстан Республикасы Мамадыш муниципаль районы Катмыш авыл җирлеге составына керүче торак пунктларда гражданнар җыеннарын әзерләү һәм үткәрү тәртибе турындагы» Нигезләмәгә түбәндәге үзгәрешләр һәм өстәмәләр кертергә:

1.1. 4.1 пунктын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:
«4.1. Әлеге статьяда каралган гражданнар җыены торак пункт яки җирлек халкының сайлау хокукына ия булган яртысыннан артык кеше катнашында хокуклы. Әгәр торак пунктта әлеге торак пунктта яшәүчеләрнең яртысыннан артыгы бер үк вакытта сайлау хокукына ия булган булса, авыл җирлеге Уставы нигезендә гражданнар җыены гражданнар җыенын үткәрү турында Карар кабул ителгәннән соң бер айдан артмаган вакытка этаплап үткәрелә. Шул ук вакытта элегрәк гражданнар җыенында катнашкан затлар тавыш бирүнең алдагы этапларында катнашмый. Гражданнар җыены карары әгәр аның өчен халык җыенында катнашучыларның яртысыннан артыгы тавыш бирсә, кабул ителгән дип санала.»;

1.2. 1.6 пунктының 7 абзацын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:
«-авыллар арасындагы территорияләрдә урнашкан торак пунктта яңа төзелгән җирлек булдыру турында, шулай ук яңа төзелгән җирлектә, әгәр дә аның сайлау хокукына ия кешеләре саны 300 дән артмаса, яңа төзелгән җирлекнең җирле

үзидарә органнары структурасын билгеләү мәсьәләсе буенча халык инициативасын тәкъдим итү максатларында;».

2. Әлеге карарны Татарстан Республикасы Мамадыш муниципаль районы авыл җирлеге стендларында урнаштырырга, Мамадыш муниципаль районы рәсми сайтында, "Интернет" мәгълүмати- коммуникацион челтәрендәге Татарстан Республикасының муниципаль берәмлекләр Порталында http://mamadysh.tatarstan.ru/ веб- адресы буенча һәм Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында (pravo. tatarstan.ru) игълан итәргә.

3. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны Катмыш авыл җирлеге башлыгыИ.Г.Габидуллинга йөкләргә.

Татарстан Республикасы
Мамадыш муниципаль районы
Катмыш авыл җирлеге Башкарма
комитеты җитәкчесе /И.Г.Габидуллин/